# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

08 05 2026 ел № 1496

Чираттагы финанс елына һәм план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты проектын төзү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставының 87 статьясы 5 пункты нигезендә, чираттагы финанс елына һәм план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты проектын үз вакытында эшләү максатында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты проектын төзү тәртибен расларга.
2. «Чираттагы финанс елына һәм план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты проектын төзү тәртибен раслау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 27 июнендәге 3375 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2026 елның 1 апреленнән үз көченә керә.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район финанс-бюджет палатасы рәисе Р.Н. Әмирхановага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Тукай муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына 1 кушымта

# Чираттагы финанс елына һәм план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты проектын төзү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты проекты Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатында, Тукай муниципаль районының социаль-икътисади үсеш фаразы нигезендә төзелә.

## II. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты проектын төзү өчен кирәкле белешмәләр

2.1. Тукай муниципаль районы бюджеты проектын вакытында һәм сыйфатлы төзү максатында, Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы җирле үзидарә органнарыннан кирәкле белешмәләр алырга хокуклы.

2.2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләрне) билгеләүче Россия Федерациясе Федераль Җыеныныа юлламасы нигезләмәләренә;

- Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлеге юнәлешләрен билгеләүче документларга;

- Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасына;

- чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләренә;

-Тукай муниципаль районының чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына; агымдагы финанс елына бюджетның көтелгән үтәлешенә;

- муниципаль программаларга (муниципаль программалар проектларына, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларына).

## III. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты керемнәрен формалаштыру

3.1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Тукай муниципаль районы бюджеты параметрларын керемнәр буенча формалаштыру түбәндәгеләрне исәпкә алып башкарыла:

- Тукай муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразы, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында гамәлдәге законнары, салымнар һәм җыемнар турында Татарстан Республикасы законнары, Тукай муниципаль

районы җирле үзидарә органнарының салымнар һәм җыемнар турында норматив хокукый актлары, шулай ук аларның фаразланган үзгәрешләре;

- Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары, Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының салым булмаган керемнәрне билгеләүче норматив хокукый актлары;

- Тукай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары тарафыннан Тукай муниципаль районы бюджетына планлаштырылган керемнәр турында мәгълүмат.

## IV. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру

4.1. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә һәм методика нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.2. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру гамәлдәге һәм кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләре буенча аерым гамәлгә ашырыла.

4.3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре дигәндә составы һәм (яки) күләме Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары, агымдагы финанс елында, чираттагы финанс елында яисә план чорында үзгәрешкә, агымдагы финанс елында тиешле йөкләмәләрне үтәүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләмен арттырып, үз көчләрен югалткан дип тануга яисә үзгәрүгә тәкъдим ителми торган (планлаштырылмый торган) шартнамәләр һәм килешүләр белән, күрсәтелгән Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын, Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын үтәү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты акчаларын алучылар тарафыннан төзелгән (төзелергә тиешле) шартнамәләрне һәм килешүләрне дә кертеп, бәйле булган ассигнованиеләр аңлашыла.

4.4. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре дигәндә составы һәм (яки) күләме Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары, агымдагы финанс елында, чираттагы финанс елында яисә план чорында үзгәрешкә, агымдагы финанс елында тиешле йөкләмәләрне үтәүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләмен арттырып, үз көчләрен югалткан дип тануга яисә үзгәрүгә тәкъдим ителә торган (планлаштырылмый торган) шартнамәләр һәм килешүләр белән, күрсәтелгән Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын, Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын үтәү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты акчаларын алучылар тарафыннан төзелгән (төзелергә тиешле) шартнамәләрне һәм килешүләрне дә кертеп, бәйле булган ассигнованиеләр аңлашыла.

4.5. Кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру гамәлдәге йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләрен беренче

чиратта планлаштырганда гамәлдәге һәм үтәлмәгән йөкләмәләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4.4. Бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль заданиене, шулай ук хисап финанс елында һәм агымдагы финанс елында аны үтәүне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## V. Социаль-икътисадый үсеш фаразы

5.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразы кимендә өч елга әзерләнә.

5.2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының социаль-икътисади үсеш фаразы ел саен Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге тарафыннан әзерләнә.

5.3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының социаль-икътисади үсеш фаразы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан хуплана һәм аны Тукай муниципаль районы Советына тәкъдим итү өчен, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты проектын кертү белән бер үк вакытта җибәрелә.

5.4. Чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы план чоры параметрларын төгәлләштерү һәм план чорының икенче елы параметрларын өстәү юлы белән эшләнә.

5.5. Социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма язуында фараз параметрларын нигезләү, шул исәптән аларны, фаразлана торган үзгәрешләрнең сәбәпләрен һәм факторларын күрсәтеп, элек расланган параметрлар белән чагыштыру китерелә.

5.6. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты проектын төзү яки карау барышында Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразын үзгәртү бюджет проектының төп характеристикалары үзгәрүгә китерә.

## VI. Татарстан Республикасының салым чыгымнары исемлеге һәм бәяләү

6.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының салым чыгымнары исемлеге Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә муниципаль программалар, шулай ук муниципаль программаларга карамаган эшчәнлек юнәлешләре киселешендә төзелә.

6.2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының салым чыгымнарын бәяләү, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, ел саен Тукай муниципаль районының Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6.3. Күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль

районының муниципаль программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

## VII. Тукай муниципаль районының муниципаль программалары

7.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының муниципаль программалары Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

7.2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль программаларын гамәлгә ашыру сроклары Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә билгеләнә.

7.3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының муниципаль программаларын эшләү һәм күрсәтелгән программаларны формалаштыру һәм гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү тәртибе Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

7.4. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының салым чыгымнары исемлеге Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль программалар, шулай ук муниципаль программаларга карамаган эшчәнлек юнәлешләре киселешендә төзелә.

7.5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә бюджет чыгымнарының һәр программага туры килә торган максатчан статьясы буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты турында карары белән раслана.

7.6. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалары, шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының элек расланган муниципаль программаларына үзгәрешләр Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм срокларда расланырга тиеш.

7.7. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының муниципаль программалары агымдагы финанс елының 15 маеннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты турында карарына туры китерелергә тиеш.

7.8. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының һәр муниципаль программасы буенча ел саен аны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү үткәрелә. Күрсәтелгән бәяләүне үткәрү тәртибе һәм аның критерийлары Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

7.9. Күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан чираттагы финанс елыннан башлап элек расланган муниципаль программаны туктату яки үзгәртү, шул исәптән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль программасын

гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен үзгәртү кирәклеге турында карар кабул ителергә мөмкин.

7.10. Тукай муниципаль районының муниципаль программалары белән Тукай муниципаль районының муниципаль программаларына туры килә торган максатларга ирешүгә юнәлтелгән муниципаль программаларны гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга субсидияләр бирү каралырга мөмкин. Күрсәтелгән субсидияләрне бирү һәм бүлү тәртибе Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының тиешле муниципаль программасы белән билгеләнә.